| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СУГУШЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>«СУГЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026елның 18 феврале № 3

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 01 мартындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 декабрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 01 мартындагы 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасының икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Узэк ур., 27 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә һәм үзенең гамәлен 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

Лениногорск муниипаль районы
« Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе А.П. Зыятдинова